ДӨРЕС КЫЙБЛА

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына Мәскәүдә йомгак ясалды

> 2

НАИЛ ВАЗЫЙХОВ:

«Шәһәр баласына сөт белән йомырканың кайдан килгәнен күрү дә кызык»

> 3



СОҢГЫ МӨМКИНЛЕК

Роналду дөнья чемпионатындагы чыгышын күз яшьләре белән тәмамлады

> 4

ТАТАР КЫЗЫ

Милләт күрке нинди булырга тиеш?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 184 (28957) | Сишәмбе | 13 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ҮКЕНЕЧКӘ КАЛМАСЫН

РОССИЯДӘ ДИСПАНСЕРИЗАЦИЯ УЗУ ТӘРТИБЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТМӘКЧЕЛӘР

Якын киләчәктә табиблар кешенең табан астын да тикшерә башларга мөмкин. Хроник авырулары булган кешеләр дә табиб юлын ешрак таптаячак. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы диспансеризация тәртибенә шундый үзгәрешләр кертергә тәкъдим иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Билгеле булганча, 18–40 яшь арасындагы кешеләр бүген әлеге төр тикшеренүне – өч елга бер, 40 яшьтән өлкәнрәкләр ел саен уза. Белгечләр исә кайбер очракларда бу тикшеренүне елга берничә мәртәбә дә уздырырга тәкъдим итә. Әйтик, берьюлы ике төрле йөрәк-кан тамыры авыруыннан интеккән кешеләр диспансеризацияне ешрак уза алачак. Әлеге төркемгә кергән чире өстенә шикәр чире, үпкә, бөер авырулары булган кешеләргә дә табиб юлын ешрак таптарга туры киләчәк. Бу үзгәрешләр гамәлгә керә калса, хроник авырулары булган кешеләр дә диспансеризацияне ешрак үтәчәк.

Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина Галиуллина соңгысын аеруча кирәкле үзгәреш дип саный.

– Яшерен-батырын түгел, хроник авырулы кешеләр арасында төрлесе бар. Кемдер, сәламәтлеген кайгыртып, диспансеризацияне вакытында узып тора. Икенче берләре моны вакытны бушка уздыру дип саный. Табибка да чире азып, соңгы чиккә җиткәч кенә күренә. Диспансеризацияне, хроник чирләре булган авырулар гына түгел, һәркем вакытында узарга тиеш. Ул бик күп чирләрне башлангыч чорда ачыкларга, үлем-китем, инвалидлык куркынычын алдан кисәтергә ярдәм итә. Диспансеризация вакытында канны тагын да җентеклерәк тикшерә башласалар да яхшы булыр иде, – дип саный белгеч.

Министрлык әзерләгән документтан аңлашылганча, эпилепсиядән интеккән кеше елга ким дигәндә ике мәртәбә профилактик тикшеренү узарга тиеш. Табиб аларның гәүдә авырлыгын, кан басымын үлчәп, кандагы глюкоза һәм холестерин дәрәҗәсен дә тикшерергә тиеш булачак. Паркинсон авыруыннан интеккән өлкәннәргә дә, елга ике тапкыр табибка күренеп, диагнозын раслап торырга туры киләчәк. Табиб кирәк дип тапса, аларны психиатрга да җибәрә алалар.

Беренче һәм икенче типтагы шикәр чире булган кешеләр исә эндокринологка елына ким дигәндә дүрт тапкыр күренеп торырга тиеш булачак. Аларга гадәти кан һәм бәвел анализлары тапшырып, кардиограмма ясатырга да туры киләчәк. Шикәр чирле кешеләрнең табан асларын да тикшерә башлаячаклар. Бу аякларның сизгерлеген, кан тамырларының торышын ачыклау өчен кирәк, ди белгечләр.

Табиб-эндокринолог Әлфия Сәлихова шикәр чирле авыруларның гына түгел, һәркемнең табан астын тикшерү яклы.

– Табан астындагы үзгәрешләр бик күп авыруларның билгесе булырга мөмкин. Шуңа күрә табан астында даими рәвештә сызлау, чәнчү, авырту сизелсә, ул гел кызып торса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк, – ди ул.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, быел республикада 2 миллион чамасы кеше диспансеризация узган. Бу – еллык планның 82 проценты үтәлгән дигән сүз. Диспансеризация узган һәр 11 кешенең берсендә теге яки бу чир ачыкланган.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының гомуми табиблык практикасы буенча штаттан тыш баш белгече Люция Хафизова барыннан да бигрәк әнә шуңа борчыла.

– Диспансеризация узмаган кеше табибка мөрәҗәгать иткәндә инде бик соң булырга мөмкин. Юкса ул кан әйләнеше, шикәр чире, сулыш юллары авыруын, яман шешне башлангыч чорда ук ачыкларга ярдәм итә. Гыйнвардан башлап атна саен халык арасында үлем-китем очракларына анализ ясыйбыз. Инфекцияле булмаган хроник авырулардан вафат булучыларның күбесе бу тикшеренүне бөтенләй узмаган. Табибка соң чиккә җиткәч – яман шешнең соңгы стадиясендә яки инфаркт, инсульт булгач кына мөрәҗәгать иткән, – ди белгеч.

Узган елның 1 июленнән Россиядә җентекле диспансеризация дигән төшенчә гамәлгә керде. Ул коронавирус белән авырып терелгән кешенең сәламәтлеген тулысынча тикшерү, мәкерле чир аркасында өзлегүләрне кисәтү өчен уздырыла. Ул гадәти диспансеризациянең бер төре булып тора. Җентекле диспансеризацияне узу өчен коронавирус белән авырганнан соң, ким дигәндә ике ай узгач, яшәү урыны буенча теркәлгән хастаханәгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аны коронавирус диагнозы рәсми рәвештә расланган кешеләр һәм ПЦР-тесты уңай нәтиҗә бирмәсә дә, ковид белән авырган кешеләр уза ала.

Табибларны авырулар белән матур итеп сөйләшергә дә өйрәтмәкчеләр. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы моның өчен махсус белешмә дә әзерләгән. Аның буенча табиб авыруга «сез» дип кенә эндәшергә, дорфа сүзләр кулланмаска тиеш. Мисал өчен, «сезнең проблема» ише сүзтезмәне дә «безнең очракта» дигән җиңелчә гыйбарәгә алмаштырырга тәкъдим ителә.

Балалар ярдәмсез түгел

Россия Хөкүмәте киләсе елда аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларга түләү өчен төбәкләргә 3,3 миллиард сум акча юллаячак. «Дәүләт башлыгы тәкъдиме белән 3–7 яшьлек һәр балага айлык пособие билгеләнә. Киләсе елда аны түләү өчен төбәкләргә өстәмә рәвештә 3 миллиард 300 миллион сум акча җибәреләчәк», – дигән Премьер-министр Михаил Мишустин.

Аның әйтүенчә, мохтаҗларга ярдәм итү чараларының берсе генә әле бу. Алар өчен бөтен ил күләмендә тулы бер ярдәм системасы булдырылачак. Шулай итеп, барлык яшьтәге балаларның ата-аналарына, булачак аналарга ярдәм кулы сузачаклар.

Исегезгә төшерәбез: 1 гыйнвардан бердәм универсаль пособие гамәлгә кертелә. Ул балалы гаиләләр һәм йөкле хатын-кызлар өчен барлык түләүләрне үз эченә ала.

Сайлатканчы тикшерәсе бар

Россия Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү яшен үзгәртү мәсьәләсен карамаган әле, чөнки ул төрле яклап тикшерү таләп итә. Үзәк сайлау комиссиясе башлыгы Элла Памфилова әнә шулай дигән. 16 яше тулган кешеләргә сайлауда катнашу хокукы бирү турындагы тәкъдимне ЛДПР вәкилләре җиткерде. Закон проекты Дәүләт Думасына кертелде.

Депутатлар үз тәкъдимен безнең илдә хокукларның бер өлешенең нәкъ менә 16 яшьтән бирелүе белән аңлата. Мәсәлән, шушы яшьтә хезмәт килешүен төзергә һәм кайбер очракларда хәтта никахлашырга мөмкин. Закон проекты авторлары фикеренчә, кеше эшли, гаилә кора, бала таба ала икән, димәк, ул хакимиятне дә сайлау хокукына ия булырга тиеш.

Карлы еллар

Үткән ял көннәрендә Казанга ярты айлык нормадан күбрәк кар «ишелеп төшкән». Якын араларда мондый явым-төшем көтелми. КФУ экология һәм табигатьтән файдалану институты профессоры Юрий Переведенцев әйтүенчә, ике тәүлек эчендә – 10 һәм 11 декабрьдә 30 мм күләмендә (декабрь нормасы – 43 мм) кар яуган. «Ике тәүлек эчендә ярты айлык нормадан артыграк кар яуды, бик күп бу», – дигән профессор. Аның әйтүенчә, кар катламы биеклеге февраль аена хас күрсәткечкә – 27 сантиметрга җиткән.

Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, без Урта диңгездән килгән көньяк циклон йогынтысында калганбыз. Мондый циклон кышын күп явым-төшем алып килә. Кар-буран Казаннан көнбатыштарак урнашкан территорияләрдә – Мәскәүдә, Түбән Новгород өлкәсендә бигрәк тә нык котырган.

Тагын икәү калган

Көзгә кергәч, республикада барлыгы 14 ярминкә узган. Татарстан фермерлары аларда җәмгысы 1 миллиард 393,7 миллион сумлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, шушы чорда шәһәр халкы 16,5 мең тоннадан күбрәк яшелчә, шул исәптән 10,1 мең тонна чамасы бәрәңге, 224,2 тонна сөт, 1,5 мең тонна ит (925,8 тоннасы – сыер ите), 500 тоннадан күбрәк он һәм 1,8 миллион данә йомырка сатып алган.

Авыл хуҗалыгы ярминкәләре, 10 сентябрьдән башлап, һәр шимбә саен уздырыла. Алар 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Сәүдәне оештыруга 32 район, 13,9 мең берәмлек транспорт җәлеп ителгән.

Яңалык

Салымлы сәлам синә!

Тау Мөхәммәткә бармаса, Мөхәммәт тауга бара дигәндәй, салымчылар үзләре эшмәкәрләр алдында хисап тота башламакчы. Ничек итепме? Эшмәкәр күпме салым түләргә тиеш икәнен исәпләп, «сәлам хаты»н айдан-айга кесә телефонына гына җибәреп торачаклар.

Автоматлаштырылган гадиләштерелгән салым салу системасы илдә быелның 1 июлендә гамәлгә керде. Ул кече бизнеска кагыла. Әлегә яңа системадан гамәлдәге елның 1 июленнән эшкә тотынган эшмәкәрләр һәм оешмалар гына файдалана алса, киләсе елдан теләге булган һәркем салымны гади итеп исәпләтә алачак.

– Яңа система эшне бермә-бер җиңеләйтәчәк, – ди Салым федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин. – Чөнки эшмәкәрләрнең салымнарны исәпләү, аларны түләүгә киткән вакытлары бермә-бер кимеячәк. Яңа салым системасы салымчы түләргә тиешле акчаны үзе саный.

Гадиләштерелгән салым системасын, тәҗрибә буларак, илнең дүрт төбәгендә сынап караячаклар. Болар – Мәскәү шәһәре, Татарстан, Мәскәү һәм Калуга өлкәләре. Хәтерләсәгез, үзмәшгульләргә салымны да иң беренче нәкъ менә шушы төбәкләрдә гамәлгә керткәннәр иде. Гадиләштерелгән салым системасына бәйле тәҗрибә 2027 елның 31 декабренә кадәр дәвам итәчәк.

Ул нәрсәдән гыйбарәт? Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, куркырлык берни дә юк. Киресенчә, салымчылар үзләре эшмәкәрләр алдында хисап тота башлаячак. Яңа салым системасыннан яшәү урыны буенча теркәлгән эшмәкәрләр һәм оешмалар файдалана алачак. Бизнес вәкилләре мөстәкыйль рәвештә салым исәпләү, декларация тапшыру, эшчеләр өчен хисап тоту, кертемнәр түләү кебек эреле-ваклы матавыклардан котылачак дип фаразлана. Урынга барып тикшерүләргә дә чик куярга вәгъдә иткәннәр. Дөрес, җиңел эшкә күчүнең шартлары да бар.

– Яңалык кече бизнеска кагыла. Шәхси эшмәкәрдә яки оешмада күп дигәндә биш кеше эшләргә мөмкин. Еллык керем исә 60 миллион сумнан артмаска тиеш. Тагын шунысы да бар: тәҗрибә рәвешендәге эш аерым исемлеккә кергән банклар белән берлектә алып барылачак. Шуңа күрә яңа системага күчәргә теләгән эшмәкәр бу банкларның берсендә исәп-хисап счеты ачарга һәм эшне фәкать шунда гына алып барырга тиеш. Эшчеләргә хезмәт хакын да банк картасына гына күчерергә ярый, – дип аңлатты идарә җитәкчесе.

Шулай итеп, эшмәкәргә салымнарны исәпләп торасы булмаячак. Яңа системаның төп өстенлеге әнә шул. Салымчылар үзләре үк теге яки бу оешмадагы бөтен керем һәм чыгымнарны чагыштырып барачак. Банклар ярдәмендә, билгеле. Кече эшмәкәрләргә сайлау мөмкинлеге дә биргәннәр. Яңа система белән эшләячәк банклар исемлегендә сигез кредит оешмасы бар. Аларның кайберләрен «Татар-информ»да узган матбугат очрашуына да чакырганнар иде. «Яңа системага күчү өчен каядыр барырга яки документлар тутырып җәфаланырга кирәкми. Моның өчен кесә телефонында махсус кушымта булдыру да җитә», – дип сөйләде «Сбербанк» вәкиле Рушан Сәхбиев.

Салымчылардан «сәлам хаты» айдан-айга килеп торачак. Ягъни гадиләштерелгән салымны ай саен түлисе.

– Эшмәкәрләр махсус кушымтада үзләре дә керемнәр һәм чыгымнарга бәйле мәгълүматка төзәтмәләр кертә ала. Моның өчен һәр айның җидесенә кадәр вакыт биреләчәк. Салым суммасы исә һәр айның унбишендә киләчәк. Аны егерме бишенә кадәр түләргә кирәк. Ярты елдан бирле гамәлдә булган яңа системага республикадагы 500ләп эшмәкәр һәм оешма кушылды инде, – диде Марат Сафиуллин.

Сүзгә-сүз

Айдар МЕТШИН, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Республика өчен, тулаем ил өчен хәзер иң мөһиме – тынычлык һәм татулык. Дәүләт мәнфәгатьләрен яклауга китүчеләрнең исән-сау булулары, көчле социаль дәүләткә әйләнүебез. Боларның барысы да Россиядә яшәүче һәрбер кешенең тормышында чагылыш таба.

(«Татар-информ»нан)

РОССИЯДӘ – ЯЛ ИТҮ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге (ВЦИОМ) мәгълүматларына караганда, быел Россиядә яшәүчеләрнең һәр дүртенчесе кунакка сирәгрәк йөри башлаган.

Кунакка йөрү
26% >> сирәгрәк / 7% >> ешрак / 56% >> элеккечә

Җәмәгать туклануы урыннарына йөрү
22% >> сирәгрәк / 30% >> элеккечә / 43% >> бөтенләй йөрми

Россиядә төшерелгән фильм-сериаллар карау
56% >> элеккечә / 13% >> ешрак / 10% >> сирәгрәк

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** 444 сум 54 тиен; гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** 980 сум 10 тиен; гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЯШЕЛ ВОДОРОД КОРИДОРЫ

Дөньяда икътисадый кыенлыклар арта һәм сәяси киеренкелек үсә. Россия нефтенең бәясенә чик кую глобаль базарда «кара алтын» бәяләренең үсүенә китермәде. Киресенчә, җир мае бәясен түбәнгә тәгәрәтте. Үткән атна дәвамында нефтьнең бер барреле 10 доллардан да күбрәккә очсызланды.

Белгечләр арзанаю дәвам итәр дип фаразлыйлар. Азия базарлары Россия нефтенә түбән бәя таләп итәләр, аны Көнбатыш куйган чиктән күпкә арзанракка алалар. Кайбер базарларда бәя 40 доллар тирәсенә кадәр төште. Лондон биржасында Brent маркасына февраль фьючерслары 76 доллар белән бәяләнә, Америкада WTI маркасының гыйнвар контрактлары 71,63 долларга кадәр түбәнәйде.

Ягулык чималына бәя төшү рецессиягә бәйле. Европада инде кризисның башлануын таныйлар. АКШның финанс министры Джанет Йеллен икътисадый мәтәлчекне 2023 елда көтә. Америка уңайрак позициядә, билгеле. Ул Европага кыйммәт бәядән газ сата, Кытайдагы җитештерү мәйданнарын үзенә кайтарып, яңа эш урыннары булдыра. Әмма шуңа карамастан бөтен планетага аваз салган кризис быргысы анда да котылгысыз рәвештә тавыш бирәчәк.

Көнбатыш илләре энергетик кризисны водород ягулыгына күчеп җиңәргә ниятли. Еврокомиссия Испаниядән Франциягә водород кудыручы магистраль торбаүткәргеч төзүне рөхсәт итәргә ниятли. Ул углеводородлардан баш тарту эрасына старт бирергә тиеш. Әлеге стратегик максат 2030 елларны күз алдында тота. 2030 елга Европа 10 миллион тонна күләмендә үз водородын җитештерүне һәм шуның кадәр үк водородны читтән сатып алуны планлаштыра. Европа берлеге бары тик «яшел водород»ка гына исәп тота. Водород алу өчен шулай ук энергия кирәк бит. Углеводородлар ягып яисә атом энергиясен файдаланып водород җитештерү кире кагыла. Россиядә дә водород җитештерү проектлары бар, аның белән дөнья базарын яулау нияте дә зур иде, әмма Мәскәү «яшел» түгел, ә «зәңгәр» (газ ягып җитештерелгән водород) яисә сары (атом энергиясе ярдәмендә алынган) водородка исәп тота. Кремль яңа төр ягулыкны Европага озата алмаячак инде. Кытай базарына өмет тота. Әмма чиннар үзләре водород җитештерүдә бөтен планетада алда атлыйлар. Күк асты илендә хәзер үк 33 миллион тонна водород җитештерелә һәм ул кирәгеннән артык. German Marshall Fund дип аталган аналитик үзәк белгечләре Кытайның бу тармакка инвестицияләрен анализлап, киләчәктә аның водород җитештерүче төп державага әвереләчәген әйтәләр. Ләкин чин водородының җитди кимчелеге бар: ул ташкүмер ягып җитештерелә һәм дөньядагы иң пычрак ягулык булып санала. Декабрь башында Күк асты иленнән Гуандун провинциясендә водородта эшләүче автомобильләр җитештерә торган беренче линия эшкә кереште дигән хәбәр алынды. Август башында исә Германиядә тулысынча водородта эшли торган беренче тимер юл линиясе эшли башлады. Күрәбез, водород киләчәк ягулыгыннан көн ягулыгына әверелеп бара.

Ләкин технологик революциягә зур куркыныч яный. Финанс кризисы дәүләтләрне зур сугыш мәйданына тезәргә җыена.

Россиядә

АКЧАНЫ КАЯН АЛАСЫ?

Россиянең финанс министры Антон Силуанов үткән атнада мөһим белдерү ясады: 2022 ел нәтиҗәләре буенча бюджет дефициты көтелгәннән ике тапкыр югарырак булачак. Ил казнасы нефтькә бәяләр төшүдән интегә. Финанс министрлыгы нефть-газ керемнәренең 23 процентка кимүен фаразлый. Димәк, казнаны тутыру өчен башка юллар эзләү таләп ителә.

Әйтик, эчке сәүдә әйләнеше арту бюджетны салымнар белән тутырырга булыша алыр иде. Ләкин бу өлкәдә дә эшләр мактанырлык түгел. Бердән, бәяләр арту фонында халык билләрне кысып бууны өстен күрә. Икенчедән, акчалы урта сыйныф чит илләргә агылды һәм матди ихтыяҗларын Урта Азия, Кавказ илләрендә һәм Төркиядә канәгатьләндерә. 24 февральдән соң Грузиядә генә дә 35 мең россияле төпләнде, диләр. Бу кечкенә Кавказ дәүләтендә кече бизнеска салымнар түбән, күпмедер вакыт рөхсәтсез һәм визасыз яшәп була. Нәтиҗәсе шул: март – июнь айларында гына да россиялеләр Грузиядә 6400 компания теркәгән.

Россиянең үзендә яшәүче хәлле халык та акчасын чит илләргә күчерү буенча ярышка чыкты. Октябрь аенда гына да чит ил банкларына 5 миллиард доллар акча күчерелгән. Россия банкларындагы депозиттан чикнең теге ягына чыгып киткән акча күләме 4,19 триллион сумга җитә, диләр. Гомумән, илдән капитал качу быел 205 миллиард долларга җиткән инде. Бу алдагы өч елда качкан капиталның гомуми суммасыннан күбрәк. Төркиядәге Fibabanka Россия һәм Беларусь гражданнарына үз карталарын башка илләрдә куллануны тыйды. Димәк, Россиядән киткән акча төрек икътисадына гына эшләргә тиеш.

Сәүдә әйләнешен мондагы халыкның керемнәрен арттырып җанландырырга булыр иде. Бездә, чынлап та, минималь хезмәт хакын арттырдылар. Хәзер ул Үзәк банк курсы буенча (ул курска чынлыкта валюта алып булмый) 241 долларга җитте. Әмма чагыштырыйк: фәкыйрь Латин Америкасы илләре Коста-Рикада минималь хезмәт хакы – 541 доллар, Уругвайда – 494. Бу җәһәттән караганда да безнең базарлар артык сөенә алмыйлар. Шуңа күрә гаҗәпләнмибез: гыйнвар – октябрь айларында ваклап сату сәүдәсе 6 процентка түбәнәйгән. Гыйнвар – февральдә 4,4 процентка арткан булган әле ул, шуннан соң түбәнгә киткән. Базарның мондый төшенкелеге бюджетка керем өстәми, әлбәттә.

Бюджетның чыгымнар өлешендә махсус хәрби операциягә каралган акча өлеше арта. Киләсе ел бюджетында «Милли оборона» чыгымнары 43 процентка артыр, диләр. Керемнәрнең байтак кимүен искә алганда, оборона чыгымнарын башка тармакларга бүленгән акчаны сизелерлек кисү хисабына гына арттырып булуын аңлау кыен түгел.

Владимир Путин махсус хәрби операциянең озакка сузылачагын әйтә, димәк, билләрне кысып буу озак дәвам итәчәк. Углеводородка бәя кискен күтәрелгән очракта, бюджетка керемнәр артыр иде, әмма хәзергә ул юнәлештә фаразлар уңай түгел.

ДӨРЕС КЫЙБЛА

МӘСКӘҮДӘ ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРЫНДА ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫНА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

Меңнән артык чара, дин белән бергә милләтне күтәрү, әһәмиятле вакыйгаларның башлангычы. Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына йомгак ясалды. Нәтиҗә ясар өчен җитәкчелек, дин, сәнгать, тарих, мәдәният әһелләре, зыялылар Мәскәүгә җыелды.

tatarstan.ru

Яңа статуста

Мәскәүнең Союзлар йорты бинасы бер көнгә татар интеллигенциясе һәм якташларның очрашу урынына әверелде. Бәйрәмнең төп чарасына кадәр кунаклар күргәзмә белән таныша торды, оештыру комитеты исә утырыш үткәрде.

Төгәлрәк әйткәндә, бу көнне «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit 2023» икътисадый саммитына әзерлек турында сөйләшү булды. Оештыру комитетын, инде күркәм гадәткә әверелгәнчә, Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин җитәкләячәк. Бу чарага бәйле төп яңалыкны да ул җиткерде: Россия Президенты кушуы буенча «KazanSummit 2023» чарасына федераль статус бирелгән.

– Яңа икътисадый чынбарлык шартларында әлеге чара безнең ил өчен стратегик әһәмияткә ия, – диде Марат Хөснуллин. – Ул Россия бизнесының ислам дөньясы илләре белән эшлекле элемтәләрен ныгытырга мөмкинлек бирәчәк. Безнең мөселман илләре белән хезмәттәшлек мөмкинлекләре зур.

Татарстан Президенты искәрткәнчә, ил Президенты кушуы буенча, ул «Россия – ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркемен җитәкли. Ул шулай ук «KazanSummit»ның нәтиҗәле икътисадый чара булуын да әйтте. Сүз уңаеннан, 2009 елдан башлап 13 саммит оештырылган. Быел гына да шул чара кысасында Казанга 6,5 меңләп кеше килде.

Федераль статус алган саммитны исә 2023 елның 18–19 май көннәрендә оештырырга тәкъдим итәләр.

Тарих китабының матур бите

Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына йомгак ясалганда мактау да, рәхмәт тә күп булды. Иң мөһиме, әлеге вакыйганың бөтен Россия буенча зурлап оештырылуын искәрттеләр.

Марат Хөснуллин, катнашучыларны котлап, ил Президентының тәбрикләү сүзләрен җиткерде. Владимир Путинның сәлам хатында әйтелгәнчә, 1100 ел тулу уңаеннан күп кенә шәһәрләрдә төрле конференция, бәйгеләр узган, дин әһелләренең хезмәтләре дөнья күргән. Бу инде ислам өммәтенең берләшүенә һәм илнең ислам дөньясында абруен күтәрергә дә ярдәм итми калмаган.

Үз чиратында, Марат Хөснуллин әлеге тарихи вакыйгага багышланган чараларның югары дәрәҗәдә узуын искәртте.

– Күп эшләр башкарылды – яңа инфраструктура корылмалары төзелә башлады, дини хезмәтләр басылды, күргәзмәләр оештырылды. Без шулай ук ислам илләрендәге дусларыбызга бик рәхмәтле. Көнбатышның усал йогынтысы шартларында без аларның ярдәмен, безнең позицияне аңлауларын һәм хезмәттәшлек итүләрен күрәбез, – диде Россия вице-премьеры.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов федераль оештыру комитетына рәхмәт сүзләрен әйтте.

– Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү безнең күпмилләтле илебез тарихында тагын бер якты сәхифә булыр дип ышанам. Ул ислам дөньясында Россия абруен ныгытырга ярдәм итәчәк, җәмгыятьтә милләтара һәм динара тынычлыкны, татулыкны ныгытуга хезмәт итәчәк, – диде республика җитәкчесе.

Үзебезне күрсәттек

Иң мөһиме: ел әйләнәсе мөселманнар, аерым алганда, татарлар дин аша үзләренең мәдәниятен дә, рухын да, милләтен дә бөтен дөньяга күрсәтә алды. Моның шулай икәнен барысы да раслый.

Дин белән бергә милләт дәрәҗәсе дә күтәрелде. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов шундый фикердә.

– Ислам диненең Болгар җирендә кабул ителүе – зур вакыйга. Россия Президенты Владимир Путинның шәхси фәрманы нигезендә 1100 еллыкны федераль дәрәҗәдә оештырырга насыйп булды. Оештыру комитетын да үзебезнең милләттәшебез – Марат Хөснуллин җитәкләде. Ел бик нәтиҗәле узды. Гомумән, динебез дәрәҗәсе күтәрелде. Рәсми төстә болай итеп билгеләп үтелә икән, бу инде синең кыйблаң дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан кабул ителә, хуплана дигән сүз дә әле, – дип уртаклашты ул. – Бу вакыйганы кыска вакытлы чара дип кенә кабул итмик. Ул безнең яшәү рәвешенә әйләнергә һәм гомеребез буе озата барырга тиеш. Ил-көннең нинди хәлдә булуын исәпкә алып, безгә кыйблабызның дөрес икәненә инанып, берләшергә һәм бердәм булу зарур. Моңа өстәп бер-беребезне таныргa, аңларга, хөрмәтле, мәрхәмәтле, игътибарлы булырга өйрәнергә кирәк. Ислам диненең кануннары исә нәкъ шуңа өйрәтә дә бит. Киләчәктә дә кыйблабызга тугры калырга кирәк.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин бу ел алып килгән төп вакыйгаларны телгә алды.

– Иң мөһиме – Коръәнне кулдан күчереп язу башланды, мәчет төзелешенә башлангыч бирелде. Нигез ташын салдык, проект эшләре дәвам итә, – диде дин әһеле. – Бу берләшү елы булды. Безгә алга таба да дус-тату яшәргә кирәк.

Ислам дине Россия тарихы белән тыгыз бәйләнгән һәм ил тормышын аннан башка күз алдына китереп булмый. Россия Иҗтимагый палатасының мәгълүмати берләшмәләрне, массакүләм мәгълүмат чараларын һәм коммуникацияләрне үстерү комиссиясе рәисе Рифат Сабитов шул хакта искәртте.

– Бүген мөселманнар – Россиянең аерылгысыз өлеше, ә ислам – халыклар бердәмлегенең бер терәге. Хәзер тарихи уртаклык һәм мәдәниятләрнең бер-берләренә тәэсир итүен алга сөрергә кирәк. Шулай ук динара низагларга юл куймау да мөһим, – дигән фикердә ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА


tatarstan.ru

Сезне бездә көтәләр

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ЭШ СӘФӘРЕ БЕЛӘН – ТӨРКИЯДӘ

Татарстан өчен Төркия – алдынгы чит ил партнерларының берсе. Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов Төркиянең Бурса шәһәрендәге «Татарстан – Төркия» бизнес-форумында шулай дип белдерде. Гадәттәгечә, Рөстәм Миңнеханов җитәкләгән делегация көнчыгыш юнәлештә ил өчен, аерым алганда, республика өчен файдалы булырдай хезмәттәшлек мөмкинлекләрен барлады.

Бизнес-форумда чыгыш ясаганчы, Татарстан Президенты Бурса губернаторы Якуп Җанболат, шәһәр мэры Алинур Акташ һәм Бурса сәнәгать һәм сәүдә палатасы идарәсе рәисе Ибраһим Буркай белән очрашты. Ике як та уртак проектлар һәм киләчәктә башкарыласы эшләр турында фикер алышты.

– Сезнең ил – Татарстанның төп чит ил партнерларының берсе. Төркия компанияләре безнең республикага якынча 2 млрд доллар күләмендә акча инвестицияләде, – дип искәртте Татарстан Президенты. Аның сүзләренчә, республикада 10 төрек заводы үз эшчәнлеген алып бара. Алга таба да үсеш өчен нигез барлыгын әйтте республика җитәкчесе.

Бурса губернаторы да Татарстан җитәкчелегенә рәхмәтен җиткерде.

– Берничә ел элек сезнең белән очрашкан идек. Ул вакытта ук ике як үсеше өчен мөһим булган очрашу үткәрдек. Хәзер инде нәтиҗәләрен күрәбез. Бурсадагы форум да ике якның бизнесын тагын да якынайтыр дип өметләнәм, – диде Якуп Җанболат.

Сүз уңаеннан, Бурса провинциясе зурлыгы буенча Төркиядә дүртенче урында тора. Анда 17 зур сәнәгать зонасы урнашкан. Провинция Төркиянең автомобиль сәнәгате үзәге булып санала.

Әйтергә кирәк, Татарстаннан Төркиягә киткән делегация дә шактый зур. Делегация вәкилләре арасында зур предприятие һәм бизнес-оешмаларның җитәкчеләре дә бар. Аерым алганда, Төркиядә КАМАЗ, Казан синтетик каучук заводы, «Триада», «Машдеталь» һәм башка предприятиеләр тәкъдим ителде.

Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, Татарстан Төркия белән хезмәттәшлеккә аерым игътибар бирә. Бу үз чиратында Россия – Төркия арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту өчен дә мөһим.

– Узган ел Төркия һәм Татарстан арасында сәүдә әйләнеше 55,8 процентка үсте һәм 563 млн доллардан артып китте, – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. – Без Төркия бизнесының алга таба да Татарстанда үз проектларын тормышка ашыруын телибез. Моның өчен кирәкле шартлар тудырырга да әзер.

Бурсада Рөстәм Миңнеханов «TOGG» автозаводында булды. Биредә Төркиянең беренче электромобилен чыгаралар. Татарстан Президенты завод белән танышкач, яңа машинада үзе йөреп карады.

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы 15 декабрь көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 15 декабрьдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

ЧЫРШЫ, ЧЫРШЫ...

Бәйрәмгә әле ике атнадан артык вакыт булса да, чыршылар инде бизәлә дә башлады. Чынына кызыгучылар да, ясалмасын сайлаучылар да бар. Матурлык тудырганда нәрсәгә игътибар итәргә?

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгыннан әйтүләренчә, нарат белән чыршы җитәрлек булачак. Министрлыкның матбугат үзәге җитәкчесе Альмира Нуретдинова әйтүенчә, Азнакай, Әлки, Әлмәт, Бөгелмә, Яшел Үзән, Лаеш, Мамадыш, Саба һәм Биектау районының Ислейтар урманчылыклары ылыслы агачлар сатарга рөхсәт алган.

– Без бәйрәмгә дип плантацияләрдә һәм питомникларда чыршыларны махсус утыртабыз. Күпләр ясалманы бизәсә дә, чынын сорап килүчеләр дә бар әле. Ни дисәң дә, һәркем үз күңеленә хушын сайлый бит. Әгәр инде чын чыршы куярга телисез икән, аны безнең питомниклардан алып булачак. Килгән кешегә чыршыны кисеп бирәбез, – ди Казандагы шәһәр яны урманчылыгы җитәкчесе Илнур Кәшәфиев. – Хәзер чыршы сатучылар күп булачак. Агачның сыйфатын да, сатучының документларын да тикшерү комачау итмәс.

Мамадыш районының Кама урманчылыгы җитәкчесе Альберт Шамилов әйтүенчә, чыршы сатып алучылар күп түгел.

– Шәһәр халкы аның хуш исенә кызыгадыр инде. Әмма дөрес сакламасаң, аның энәләре коелып бетәчәк. Кисеп алынган агачка караганда, махсус савытта үсеп утырганын бизәвең яхшырак. Без урманны саклау яклы, – ди ул.

Казанның Вознесение бистәсендә яшәүче Гөлфия Хаҗиева, өйдә чыршы бизәмибез, ди.

– Балалар бик сорый. Алар инде бәйрәм көтә. Әмма без өйгә чыршы кертмибез. Ясалмасы да, чыны да кирәк түгел. Йорт сатып алганда ишегалдында чыршылар бар иде, үзебез дә утырттык. Шулар әкренләп үсеп килә. Кар явуга һәрберсен бизәп, утлар куябыз. Ишегалдыбыз үзенә күрә бер әкияти мәйданчыкка әйләнә, – ди ул.

Әмма чыршы әкият кенә түгел, мәшәкать тә китереп чыгарырга мөмкин. Республикада «Ель» операциясенә әзерләнәләр. Әлеге чара 20–31 декабрьдә узачак. Агачларны законсыз кисү, урман утыртмаларына зыян салган кешегә 3 мең сумнан 4 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 20 мең сумнан 40 мең сумга кадәр, юридик затларга 200 мең сумнан 300 мең сумга кадәр штраф каралган. Моннан тыш, агачны законсыз кискән кеше урманнарга китерелгән зыянны капларга тиеш. Әгәр урманга 5 мең сум һәм аннан да күбрәк зыян салына икән, моның өчен җинаять җаваплылыгы да каралган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

Быел Татарстанда бәйрәмгә дип **8050** данә чыршы һәм **32** тонна ылыслы ботак әзерләнәчәк. Алар **55** урында сатылачак. Узган ел урманчылар **6960** данә чыршы сатып, **2,7** миллион сум акча эшләгән.
Чыршы бәяләре (сумнарда):
✓ 1 метрлысы – **350;**
✓ 2 метрлысы – **450;**
✓ 3 метрлысы – **700;**
✓ 4 метрлысы – **1700;**
✓ 5 метрлысы – **2000;**
✓ ылыслы ботакның **1** тоннасы – **3900.**



КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен Чаллы шәһәренең «Игорь Лерманның камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе – директоры **Лерман** Игорь Михайлович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Нигъмәтҗанов** Ринат Галимҗан улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсе наркотик матдәләрнең синтетик төрләренең, психотроп, көчле тәэсир итүче, потенциаль куркыныч тудыра торган яңа психоактив матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы көрәшү бүлеге башлыгы урынбасары – потенциаль куркыныч тудыра торган яңа психоактив матдәләрнең законсыз әйләнешенә каршы көрәшү бүлекчәсе башлыгы, полиция подполковнигы **Федоров** Роман Игоревичка, **«АК БАРС Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе мәгълүмат-аналитика бүлеге баш киңәшчесе **Никитина** Арина Ринат кызына, «Татарстан Республикасының теннис федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасының оештыру мәсьәләләре буенча вице-президенты **Афанасьев** Виталий Дмитриевичка, «Татарстан Республикасының теннис федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасының спорт эше буенча вице-президенты **Жуков** Геннадий Кимовичка, Россиянең спорт мастеры **Кодермәтова** Полина Эдуард кызына; Россиянең спорт мастеры **Кодермәтов** Эдуард Дамир улына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесе эшләр идарәчесе **Әгъләмов** Радик Рим улына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Апас районы территориаль бүлекчәсе исәп һәм хисап бүлеге башлыгы **Бикчәнтәева** Рәмзия Нурулла кызына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының мәгълүматлаштыру бүлеге өлкән белгече **Гәрәев** Булат Гарифҗан улына, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесенең әхлакый-психологик тәэмин итү бүлеге тәрбия эше бүлекчәсе өлкән инспекторы, полиция подполковнигы **Мәрданов** Илдар Рәфкать улына, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы документларны эшкәртү һәм исәпкә алу эшләрен башкару 3 номерлы бүлеге башлыгы **Назмиева** Гөлназ Тәлгать кызына, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы белешмәләрне әзерләү бүлеге башлыгы **Сәйфиева** Лилия Илһам кызына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Субаева** Светлана Андреевнага, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының дежур часте смена башлыгы, полиция подполковнигы **Титов** Герман Генадиевичка, «На каждый день» мәгълүмат-нәшрият үзәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш мөхәррире (Люберцы шәһәре) **Хансверов** Рөстәм Хөсәен улына, Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе референты **Гатин** Илдар Мәхмүт улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

ҮЗЕБЕЗНЕКЕН САГЫНУ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чыршы бәйрәмендә чит ил геройларына урын юк! Чиләбе шәһәрендәге балалар бакчаларының берсендә тәрбиячеләр әти-әниләргә әнә шундый шарт куйган: Человек-паук, Бэтмен, Хагги Вагги булып киенеп килмәскә! Бездә Яңа ел тамашаларында мондый чикләүләр юк анысы. Әмма шулай да анда үзебезнең милли геройларыбызга урын бармы?

Тәрбиячедән сора!

Чиләбе тәрбиячеләре әти-әниләргә Яңа ел тамашасында балалары өчен чит ил геройларын түгел, Куян, Аю, Кар бөртеге, Кәнфит һәм башка образларны сайларга киңәш иткән. Шәһәр мәгариф идарәсендә исә бу хәлне болай аңлатканнар: Яңа ел тамашалары рус әкиятләренә багышлана, шуңа күрә анда Америка супергеройлары бик үк туры килеп бетми. Бүгенге шартларда бигрәк тә.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, федераль стандартларда балалар бакчалары программасы өчен традицион бәйрәмнәр, чараларга багышланган «Мәдәни ял эшчәнлеге» бүлеге бар.

– Бакчаларда иртәнге чаралар, шул исәптән Яңа ел тамашалары да шуңа нигезләнеп төзелә. Моның өчен классик, халык, шулай ук чит ил әсәрләре сайлап алына. Россия, Татарстан, Идел буе халыклары композиторлары, шагыйрьләре, язучылары иҗаты кулланыла. Ниндидер костюм сатып алганчы, башта тәрбиячедән чараның темасын белешергә кирәк. Бәлкем, балага геройны тәкъдим итеп, костюмны бакчада бергәләп сайларлар, – дип җавап бирделәр матбугат үзәгендә.

Мәгънәсез геройлар

Яңа ел кәефе сизелә башлады. Кибетләрдә дә, балаларын ияртеп, чыршы уенчыклары, битлекләр сайлаучы әти-әниләр шактый күренә. Әти-әниләр арасында заманча геройларны хуплаучылар да, үзебезнекен өстен күрүчеләр дә бар. Человек-паукны бакчада тыеп кына бала Шүрәлене якын итә башлармы? Телевизор һәм телефон экраннарында чит ил геройлары бит.

Сабыен Казан читендәге Царево бистәсендәге «Тал» бакчасына йөртүче Айгөл Гайсина күп нәрсәнең әти-әнидән торуын әйтә. Гел бала җырын җырлап кына да торып булмый бит.

– Үзебезнең татар геройлары онытылып бара. Без үскәндә әти-әниләр Яңа елга Су анасы, Убырлы, Шүрәле, Аю, Бүре, Кәҗә, Кар бөртеге, Яңа ел киемнәре әзерли иде. Хәзер исә Хагги Вагги, Кисси Мисси һәм башка геройлар киемнәренә акча түгәләр. Минем баланыкы иң яхшысы булырга тиеш дигән ярышу бар. Улыбыз Адил бәйрәмдә Аю булып киенәчәк, – ди Айгөл Гайсина. – Мәктәп, бакчаларда Хэллоуинны үткәрәләр. Мин моңа тискәре карыйм. Безнең үзебезнең бәйрәмнәр дә күп бит. Әйе, безнең заманда да клоун, ковбой, индеец геройлары булды, әмма алар әле күңелгә ятышлы иде. Хәзер бит алар куркыныч. Күзләре акайган, авызлары колакка җиткән гибрид Хагги Ваггины күрсәң, аңыңны югалтып егылырсың.

Татар әти-әниләр комитеты әгъзасы, тәрбияче Мөслимә Гыйльманова да Хагги Ваггины бөтенләй мәгънәсез герой дип саный.

– Әти-әниләрнең акча түгеп, шушы уенчыкны сатып алуына шаккатам. Аның куркыныч кыяфәте балада шундый ук халәт барлыкка китерә. Мондый мәгънәсез уенчык кирәк түгел дип саныйм. Яңа ел костюмы турында әйтәсе дә юк. Үз балама беркайчан да андый образ сайламас идем, – ди Мөслимә Гыйльманова.

Психолог киңәше

Наилә БӘШИРОВА, «Жасмин» үзәге психологы:
– Бөтен нәрсәдән дә качып булмый. Балалар тормышта явызлыкның да бар икәнлеген белеп үсәргә тиеш. Әгәр начарлык барлыгын белмәсә, ул югалып калырга мөмкин. Балалар дөньяны – бер, олылар икенче төрле кабул итә. Бәлкем, Человек-паук сабый өчен бик яхшы геройдыр. Яхшы һәм каршылыклы геройлар да булсын. Безнең әкиятләрдә дә Убырлы кебек тискәре образлар бар. Иләмсез уенчыклар баланы боза дип уйламыйм. Әгәр бала гел шуны сайлый икән, моны үзеннән сорагыз. Бәлкем, ул аны үзенең яклаучысы дип кабул итәдер. Усал геройга мөкиббән китү усал булып үсәчәк дигән сүз түгел. Тәрбиячеләрнең нияте нинди икән соң? Хәзер хәрби операция бара, шуңа күрә чит ил геройлары безгә кирәк түгел, дип әйтүләреме? Әллә тормышта болай да агрессия күп, бераз гына киметик, диләрме? Менә шунысын да белергә кирәк. Теге яктагыларны дошман дип күрсәтү, киресенчә, балага зыян гына китерергә мөмкин.

Кем ул Туган батыр?

«Туган авылым» милли-туристик үзәгенә нигез салучы, «Туган батыр» проекты авторы Радик Абдрахмановның да фикерен сораштык.

– Чит ил әкиятләрендә, мультфильмнарында төрле геройлар бар. Безнең балалар алар белән таныш. Әмма, кызганыч, яшь буын татарның каһарманнарын белми. Шуңа күрә без киләчәк буынга үрнәк булырдай үзебезнең героебызны тудырырга булдык. Геройның исеме – Туган, ягъни бөтен кешегә дә туган, якын кеше. Туган батыр – күп кенә әкиятләребезне, риваятьләребезне берләштереп торучы милли каһарман. Туган батыр образында безнең халкыбызның батыр уллары, көчле рухлы яклаучылары, саклаучылары, аларның холкы чагыла, – ди Радик Абдрахманов.

«Әкият» курчак театры сәнгать җитәкчесе Илгиз Зәйнинең дә фикерен сораштык:

– Без үзебез илебез каһарманнарын кулланабыз. Милли геройлар бар, әлбәттә. Россиядә ничә төрле милләт яши. Һәркайсының – үз фольклоры. Бездә төрле батырлар, Шүрәлеләр, Су аналарыннан башлап, урманнарыбызда яшәүче һәрбер җанварга кадәр бар. Яңа ел тамашалары да әзерләдек.

Сүз уңаеннан, нәни тамашачыларны әлеге театрда «Тылсымлы Яңа ел төше» дип аталган могҗизалы тамаша көтә. Балалар өчен Кыш бабай, Кар кызы катнашында әйлән-бәйлән оештырылачак. Яңа ел тамашалары татар телендә 24 декабрь һәм 4 гыйнвар көннәрендә булачак.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Рамилә СӘХӘБЕТДИНОВА, «Шаян ТВ» каналының башкарма директоры, баш мөхәррире:
– Безнең телеканалның үз персонажлары бар. Ул – Шаян, Биби, этебез Маэмай, мәчебез Мияу. Балалар менә шул персонажларны ярата. Мин үзебезнең мохиттәге, үзебез уйнап үскән персонаж, курчаклар яклы. Татар халкында милли геройлар күп бит. Әйтик, Шүрәле, Су анасы, Акбай... Аларны Яңа ел тамашаларына кертергә кирәк. Мәсәлән, без Чыршы бәйрәмен «Шаян ТВ» геройлары белән әзерләдек.

Нәфисә ХӘЙРУЛЛИНА, актриса:
– Яңа ел тамашасына баланың Человек-паук костюмы киясе килә икән, кисен. Японнар биш яшькә кадәр балаларына бөтен нәрсәне рөхсәт итә, аннан акрынлап тыя башлыйлар. Мине дә әни шулай тәрбияләде. Гел ярамый дип тору яхшыга түгел. Мин баламны бөтен әдәбият белән таныштырам. Ул Шүрәлене дә укысын, Гарри-Поттерны да... Бакчага баргач, башкалар янында аптырап калмасын. Улыбыз Даниэль Яңа елда Гарри-Поттер булып киенәчәк, узган ел Человек-паук булам дигән иде.

Кунак көткәндә

КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ ТУРИЗМ ТУРЫНДА НИЛӘР УЙЛЫЙ?

Лобач тавы, Юрьев мәгарәсе, данлыклы виноград бакчасы... Кама Тамагын таныткан иң билгеле урыннарның берничәсе генә бу. Тырыш халкы, оста һөнәрчеләре белән дә данлыклы ул. Район бүген ниләр белән яши? Халыкны нәрсә борчый? Киләчәккә нинди планнары бар? Район башлыгы Наил ВАЗЫЙХОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Сезнең районны туристлар үз итә. Бу юнәлештә нинди планнарыгыз бар?

– Бездә булып киткән кешеләр алдаларга ирек бирмәс. Кама Тамагы – бай табигатьле, республикадагы иң матур район. Без туризм тармагын үстерү өчен менә дигән җирлектә яшибез. Яр буе полосасы гына да 75 чакрымнан арта. Бездәге табигать искиткеч. Лобач тавының даны еракларга таралган. Туризм тармагында башкарасы бик зур эшләребез бар. Аеруча саклана торган табигать зонасы территорияләрен үзләштерергә җыенабыз. Бездә ирекле туризм зур үсеш алган. Безнең бурыч – ирекле туризмнан контрольдә тотыла торган туризмга күчү. Юкса без бүген районга төгәл генә күпме турист килгәнен якынча гына әйтә алабыз. Ул контрольдә тотылмый. Бу бит туристларның куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен дә кирәк. Без бит әле урманнарыбызны, табигый байлыкларны да сакларга тиеш. Әйткәнемчә, ирекле туризм бик нык үсештә. Кешеләр палаткалар белән килеп ял итә. Утынны үзләре белән алып килмиләр, билгеле. Урманнардагы агачларны кисәләр, машина белән дә таптап керәләр.

Безнең район Юрьев мәгарәсе белән дә данлыклы. Бездә балыкчылык өчен дә менә дигән урын. Моның өчен махсус базаларыбыз да бар. Дөрес, аларны да үстерәсебез бар әле. Кыш көне безгә көненә 1,5–2 меңләп кеше балыкка килә. Җәй көне дә атна ахырында шул чама кеше җыела. Киров, Ульян өлкәләре, Чувашия Республикасы, Мәскәү, Тольяттидан ук балык тотарга килүчеләр бар. Хәтта элек-электән балыкчылык төбәге саналган Әстерханнан да хәзер безгә киләләр. Шуңа күрә безгә авыл хуҗалыгы, сәнәгать белән беррәттән, туризм тармагын да үстерергә кирәк. Кеше бернәрсәсез килеп, бөтен әйберне бездә арендага алып, тыныч күңел белән рәхәтләнеп ял итәрлек булсын. Бу – үз чиратында яңа эш урыннары да пәйда булачак дигән сүз.

:: Соңгы арада авыл туризмы турында да күп сөйләнелә бит.

– Авыл туризмын үстерү турында да уйланабыз. Халкыбыз бик тырыш, сәләтле. Менә шуны лаеклы рәвештә күрсәтәсе иде. Алар үзләренең һөнәрләрен, эшчәнлекләрен танытып кына калмыйча, авыл туризмы ярдәмендә акча да эшли ала бит. Туристны ишегалдына алып кереп, шул ук тавык, кәҗә, сарык, сыер кебек йорт хайваннарын күрсәтеп чыгуның да бер авырлыгы юк бит. Шул ук шәһәр баласына өстәлдәге сөт белән йомырканың кайдан килгәнен үз күзләре белән күрү кызык булачак. Гап-гади сыер савудан да тамаша ясарга мөмкин. Авылларда, күршеләргә үзара берләшеп, мастер-класслар да уздырырга була. Кул эшләренә, аш-су серләренә өйрәтү дә кызык. Туристларга авыл мунчасына керү дә рәхәтлек бирәчәк. Кичен клубларда берәр чара уздырырга мөмкин. Кыскасы, авыл туризмы – авыл җирендә кооперация ясау өчен менә дигән сәбәп. Ике көнлек мондый авылча ял өчен туристлар акчасын кызганмаячак. Уйласаң, тагын әллә нәрсәләр оештырырга мөмкин. Әлегә авыл халкы бу тәкъдимнәремне чынга алмый, көлемсерәп кенә карый. Шулай да якын киләчәктә бу эшне дә оештырырбыз дип уйлыйм.

:: Авыл дигәннән, аны яшәтүнең төп юлларын нидә күрәсез?

– Бу очракта иң төп сорау эш мәсьәләсенә килеп тоташа. Авылның үз клубы, мәктәбе булырга һәм ул гөрләп эшләп торырга тиеш. Аларсыз авыл – үлгән авыл. Кызганыч, авылда яшәүчеләр саны елдан-ел кими бара. Яңа туган балалар саны да кими. Бүген безнең һәр авылда ФАП бар. Узган ел аларның һәркайсына югары тизлекле интернет кертелде. Фельдшер теләсә кайсы вакытта район үзәк хастаханәсе табиблары белән онлайн рәвештә элемтәгә чыга, киңәшләшә ала. Булдыра алган кадәр бөтен мөмкинлекләрне тудырып, яшьләрне авылда саклап калдырасы иде. Юкса соңгы елларда авылда гына түгел, район халкының саны да кими бара. Моңа өстәп әле аларның олыгаюы да күзәтелә. Безгә, нигездә, лаеклы ялга чыккан кешеләр кайтып төпләнә. Яшьләр шәһәргә агыла. Бу исә якын киләчәктә районда яшәүчеләр саны тагын да кимеп, эш урыннары кыскарырга, мәктәпләр ябылырга мөмкин дигән сүз. Шуңа күрә яшьләрне ничек тә үзебездә калдырасы иде. Халык җыеннарында да гел шуны искәртәм.

:: Кама Тамагы Казанга якын урнашкан. Файдасы да бар, уйланырлык ягы да. Әйтик, яшьләрне районда калдыру өчен нәрсә эшләнә?

– Бездә яшьләрне авыл, район җиренә җәлеп итүне күздә тоткан бик күп программалар эшләп килә. Клублар төзелә, төзекләндерелә. Эш урыннары булдырыла. Бүген бездә 130лап буш вакансия исәпләнә. 47 кеше исәптә тора. Яшьләрне максатчан укытуга да зур өстенлек бирәбез. 4 ел укыганнан соң безгә эшләргә кайткан яшьләргә шартлар тудырырга тырышабыз. Әйтик, «Аурус» оешмасы Казандагы авыл хуҗалыгы университеты, ветеринария академиясендә студентлар укыта. Аларга стипендия түли. Укыганнан соң районга эшкә кайткан яшьләргә йортлар да төзеләчәк. Бүген авылда да яшәү өчен шартлар шәһәрдән калышмый. Җимерек хәлдәге, буш яткан ферма, биналар бар. Без аларны крестьян-фермер хуҗалыкларына, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга тапшырырга әзер. Айлык түләвен бик аз гына итеп, арендага бирү мөмкинлеге бар. Авыл хуҗалыгы районы саналсак та, бездә өч сәнәгать оешмасы да эшләп килә. Авыл хуҗалыгы күрсәткечләре буенча республикада алдынгы сафларда булмасак та, акрынлап күрсәткечләрне яхшыртырга исәп.

Әңгәмәдәш – Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КАРАР

07.12.2022 ел Казан ш. № 1298

Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында

Яңа ел бәйрәме чараларында янгын куркынычсызлыгын, гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затларның мөлкәте, дәүләти яки муниципаль мөлкәтнең иминлеген тәэмин итү максатыннан чыгып, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 21 декабрь, 1994 ел, № 69-ФЗ Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 18 май, 1993 ел, № 1866-XII Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы территориясендә 2022 елның 19 декабреннән 2023 елның 8 гыйнварына кадәр янгынга каршы махсус режим билгеләргә.

2. Түбәндәге чикләрдә урнашкан территорияләрдә янгынга каршы махсус режимның гамәлдә булу чорында 1–3 класс хәвефлелектәге пиротехника әйберләреннән (бенгаль утларыннан, хлопушкалардан тыш) файдалануны тыюны билгеләргә:

сәнәгать, транспорт инфраструктурасы объектлары (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы объектлары (шул исәптән линия объектлары) чикләреннән 500 метр;

торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләрнең күпләп булу объектлары, автомобиль юллары, шәхси йортлар чикләреннән 30 метр;

күпфатирлы торак йортлардан 30 метр ераклыкта.

3. Янгынга каршы махсус режимның гамәлдә булу чорында үзләреннән 30 һәм 500 метр ераклыкта пиротехника әйберләреннән файдалану тыелган объектлар исемлеген (кушымта итеп бирелә) расларга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына янгынга каршы махсус режимның гамәлдә булу чорында үзләреннән 30 һәм 500 метр ераклыкта пиротехника әйберләреннән файдалану тыелган өстәмә объектларны (бу карар нигезендә билгеләнгән исемлеккә кертелмәгән) билгеләүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

үзләренең ведомствосы карамагындагы оешмаларда Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын әзерләү һәм үткәрү чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар комплексын хәл итәргә;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының аянычлы нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын үткәрү урыннарын килештерергә;

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затларны янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча укыту-өйрәтүне оештырырга;

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын үткәрү чорында дежурлар санын арттырырга;

үзләренең ведомствосы карамагындагы оешмаларның ябык бүлмәләрендә ут чыгара торган пиротехника әйберләрен саклау һәм кулланугa юл куймаска.

6. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

2022 елның 15 декабренә кадәр Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре көннәрендә янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү турында белешмәлек эшләргә;

халыкка Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү турында мәгълүмат җиткерүне оештырырга.

7. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының аянычлы нәтиҗәләрен юкка чыгару министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә тәкъдим итәргә:

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын үткәрү урыннарын учетка алуны, бәйрәм үткәрүгә җәлеп ителгән объектларда закон кысасында күзәтчелек һәм профилактик чаралар үткәрүне;

Россия Федерациясе Нацгвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе территориаль подразделениеләре хезмәткәрләре белән берлектә тиешсез сәүдә урыннарында пиротехника әйберләрен сатуны ачыклау һәм сатуга юл куймау буенча территорияләргә күчмә тикшерүләр оештыруны һәм үткәрүне.

8. Россия Федерациясе Нацгвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Россия Федерациясе нацгвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча подразделениеләре көчләрен һәм средстволарын хезмәткәрләрнең (хәрби хезмәткәрләр) патрульлек итү маршрутларында янгын очракларына, кешеләрне коткару буенча кичекмәстән чаралар күрүгә, зыян күрүчеләргә табибка кадәр беренче ярдәм күрсәтүгә һәм янгын чыганакларын янгын сүндерү расчетлары килгәнче беренчел (кул астындагы) янгын сүндерү чаралары белән бетерүгә юнәлдерүне тәкъдим итәргә.

9. Татарстан Республикасы муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдим итәргә:

пиротехника әйберләрен таратуда һәм куллануда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итүне;

халык, юридик затлар, шул исәптән пиротехника әйберләрен ваклап сатуны хәл итүче юридик затлар арасында бу карарның нигезләмәләрен үтәү, шулай ук пиротехника әйберләрен таратуда һәм куллануда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү ягыннан аңлату эшен үткәрүне оештыруны;

2022 елның 15 декабренә кадәр гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юкка чыгару һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияләр утырышларында Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәре чараларын үткәрү урыннарының янгын куркынычсызлыгы торышы мәсьәләләрен карап тикшерүне;

янгын сүндерү техникасы һәм янгын сүндерүгә көйләнгән техника белән ихтыяри һәм муниципаль янгын сагы әгъзаларының тәүлек әйләнәсендә дежур торуын оештыру буенча чаралар комплексын хәл итүне;

оператив хезмәтләрнең һәм оешмаларның Яңа ел бәйрәме чараларына һәм салкыннар чорына әзерләнү мәсьәләләрен тикшерүне;

урамнардагы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су җыю өчен шартлар тудыру, шул исәптән төзек булмаган су чыганакларын ремонтлауны, су башняларын кышкы чорда су җыю өчен тиешле җайланмалар белән, табигый сулыкларны катмый торган бәкеләр белән тәэмин итүне, су чыганакларына килү юлларын кардан чистартуны оештыру буенча чаралар комплексын хәл итүне;

халыкка янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары тирәсендә шәхси автотранспортны куярга ярамавы турында хәбәр итүне, кирәк булганда, су чыганакларына янгын сүндерү автомобильләренә килүгә комачаулаган автотранспортны эвакуацияләүне оештыруны;

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының аянычлы нәтиҗәләрен юкка чыгару министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе һәм Россия Федерациясе Нацгвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше территориаль бүлекләре (бүлекчәләре) белән килештереп, пиротехника әйберләрен сату урыннарында иминлекне тәэмин итү чараларын күрүне;

пиротехника әйберләрен саклау һәм сату шартларына мониторинг буенча комиссияләр булдыруны;

урам чыршыларын бизәүдә сертификатлаштырылган электр гирляндалары куллануны;

пиротехника әйберләрен кулланганда иминлек таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештыруны;

янгын куркынычына бәйле вазгыять катлауланган очракта тиешле территорияләрдә пиротехника әйберләрен куллануны тыюны;

2022 елның 19 декабренә кадәр һәр торак пунктта пиротехника әйберләрен куллану урыннарын билгеләүне, аларны куллануга контрольне, шул исәптән «Төнге сәгатьләрдә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 12 гыйнвар, 2010 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренең үтәлешенә контрольне тәэмин итүне һәм бу хакта халыкка хәбәр җиткерүне;

2022 елның 31 декабреннән 2023 елның 8 гыйнварына кадәрге чорда торак йортларда гражданнар белән профилактик әңгәмәләр оештыру максатыннан чыгып, шул ук вакытта күпбалалы гаиләләрнең, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарның һәм эчкече гражданнарның яшәү урыннарын аерым игътибар үзәгенә алып, Дәүләт янгынга каршы хезмәт хезмәткәрләреннән, ихтыяри янгын сагы әгъзалары, Россия Федерациясе Нацгвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе территориаль подразделениеләре һәм полиция (килешү буенча) хезмәткәрләреннән, җирле үзидарә органнары, муниципаль районнар (шәһәрләр) башкарма комитетлары административ-техник комиссияләре, халыкны социаль яклау идарәләре (бүлекләре) хезмәткәрләреннән торган профилактика төркемнәрен оештыруны.

10. Тәкъдим итәргә:

пиротехника әйберләрен җитештерү, саклау һәм сату белән шөгыльләнүче юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә пиротехника әйберләрен сату һәм алардан файдалануда янгын куркынычсызлыгы буенча Россия Федерациясе законнарын тайпылышсыз үтәүне тәэмин итүне;

ягулык салу станцияләреннән һәм комплекслардан файдаланучы юридик затларга һәм хосусый эшмәкәрләргә югарыда телгә алып үтелгән объектлар биналарын һәм территорияләрен бизәгәндә шартлаудан саклануның тиешле дәрәҗәсенә ия булмаган электр гирляндаларын һәм башка иллюминация кулланмауны;

Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сату белән шөгыльләнүче оешмалар җитәкчеләренә законда билгеләнгән тиешле сертификатларга (туры килү турында декларацияләр) ия булмаган пиротехника әйберләрен һәм электр гирляндаларын, шулай ук техник документларында янгын куркынычсызлыгы күрсәткечләре һәм алар белән эш итүдә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән Яңа ел бизәкләрен, ясалма чыршыларны сатуны тыю буенча чаралар күрүне;

үзләренең балансында янгын сүндерү өчен урамда су белән тәэмин итү чыганаклары булган предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрүне, шул исәптән янгын сүндерү автомобильләренең су чыганакларына тоткарлыксыз килүен тәэмин итүгә, шулай ук су чыганакларын кар һәм боздан үз вакытында чистартуга юнәлдерелгән чаралар күрүне;

гражданнарга пиротехника әйберләрен рөхсәтсез куллану очраклары турында «112», «01», «02» ашыгыч оператив хезмәтләр телефоннары аша, шулай ук уңайлы башка ысуллар белән дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җиткерүне.

11. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү чаралары турында халыкка мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәргә.

12. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 07.12.2022 елның № 1298 карары белән расланды

Янгынга каршы махсус режимның гамәлдә булу чорында үзләреннән 30 һәм 500 метр ераклыкта пиротехника әйберләрен куллану тыелган объектлар исемлеге

500 метр ераклыкта

1. Сәнәгать объектлары:

химия объектлары һәм производстволары:

металлургия, машина төзелеше һәм металл эшкәртү объектлары һәм производстволары;

рудалар һәм руда булмаган файдалы казылмалар чыгаручы оешмалар;

төзелеш сәнәгате оешмалары;

агач эшкәртү оешмалары;

текстиль сәнәгать объектлары һәм җиңел сәнәгать производстволары;

терлекчелек продуктларын эшкәртүче оешмалар;

азык-төлек продуктларын һәм тәм өсти торган матдәләр эшләү-эшкәртү буенча сәнәгать объектлары һәм предприятиеләр;

минераль ягулык яндырганда электр һәм җылылык энергиясе җитештерүче оешмалар;

микробиология сәнәгате оешмалары.

2. Транспорт инфраструктурасы объектлары:

вокзаллар, метрополитен, елга портлары, аэродромнар, аэропортлар;

элемтә, навигация һәм транспорт средстволары хәрәкәте белән идарә итү системаларының объектлары.

3. Ягулык-энергетика комплексы объектлары:

электр энергетикасы, нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть-химия, газ, ташкүмер, сланец һәм торф сәнәгате объектлары;

нефть продуктлары белән тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итү һәм газ белән тәэмин итү объектлары;

ягулык-энергетика комплексының линия объектлары (электр челтәрләре, магистраль газүткәргечләр, нефтьүткәргечләр һәм нефть продуктлары үткәргечләр).

30 метр ераклыкта

4. Автомобиль юллары.

5. Торак-коммуналь хуҗалык объектлары:

торак фонды, кунакханәләр, тулай тораклар;

торак-коммуналь хуҗалык объектларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау өчен билгеләнгән оешмалар;

халыкны газ, җылылык һәм электр уты белән тәэмин итү объектлары.

6. Авыл хуҗалыгы объектлары:

терлек асрый торган хуҗалыклар (дуңгыз абзарлары, сыер абзарлары, питомниклар, ат абзарлары, җәнлек фермалары);

кошчылык фермалары;

теплица һәм парник хуҗалыклары;

җиләк-җимеш, яшелчә, бәрәңге, ашлык саклагычлар;

ит, сөт эшкәртү, икмәк һәм икмәк-күмәч ризыклары җитештерү предприятиеләре һәм цехлары;

агулы химикатлар һәм минераль ашламалар саклау өчен складлар;

орлыкларны эшкәртү һәм агулау предприятиеләре;

сыекландырылган аммиак складлары;

терлек азыгы әзерләү цехлары, азык-төлек калдыкларын куллануны кертеп;

йөк автомобильләрен һәм авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау, аларга техник хезмәт күрсәтү һәм саклау буенча гаражлар һәм парклар;

матди складлар.

7. Кешеләрнең күпләп булу объектлары:

дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ биналары;

мәдәният, спорт, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, җәмәгать туклануы объектлары, дәүләт яшьләр сәясәте объектлары;

сәүдә-күңел ачу үзәкләре һәм офис үзәкләре.

8. Яшәү объектлары:

күпфатирлы йортлар;

шәхси йортлар.

Спорт

Туп батмый ул елгада

РОНАЛДУ ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНДАГЫ ЧЫГЫШЫН КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ БЕЛӘН ТӘМАМЛАДЫ

vk.com

Дүртәү генә калдылар. Атна ахырында футбол буенча Катарда узучы дөнья чемпионатының ярымфиналына чыккан командалар ачыкланды. Аргентина белән Хорватия һәм Франция белән Марокко арасындагы очрашулардан соң төп матчта кемнәрнең туп тибәсе билгеле булачак. Дөньядагы иң шәп ике футболчының берсен елаткан Марокко исә чемпионатның төп ачышына әверелде. Ә французларга рәттән икенче мәртәбә чемпион исемен яулау бик кыйммәткә төшәргә мөмкин.

Беренче көннәре буш трибуналар, җенси азгынлык кебек спортка бернинди катышы булмаган вакыйгалар белән истә калган дөнья чемпионатында, ниһаять, футбол беренче планга чыкты. Финал якынлашкан саен, көрәш кискенләшә, футбол тарихында яңа сәхифәләр языла. Аларны бик озак искә алачаклар, гәпләшәчәкләр һәм тикшерәчәкләр әле. Анысы киләчәк өчен. Бу көннәрдә исә спорт сөючеләр арасындагы төп бәхәскә нокта куелырга тора. Кем яхшырак: Лионель Андрес Месси Куччиттинимы, әллә инде Криштиану Роналду душ Сантуш Авейрумы? Инде дистә ел дәвамында футболга мөкиббән халык әнә шул сорауга җавап таба алмый интегә. Дөресрәге, бу ике егет җанатарларны ике төркемгә бүлде. Алар яңарткан рекордлар, керткән туплар һәм эшләгән акчаны санап бетерерлек түгел. Барысы да бар, әмма берсенең дә дөнья чемпионы булып танылганы юк. Быелгы чемпионат исә – соңгы мөмкинлек. Мессига – 35, Роналдуга исә – 37 яшь. Аларның тагын дүрт елдан җыелма команда составында уен кырына чыгасын күз алдына китерү кыенрак.

Аргентина җыелма командасы Голландияне пенальтилар ярдәмендә булса да отып, Лионельның төп хыялына таба тагын бер адым ясады. Көньяк Америка егетләре үзләренең лидерлары өчен барысын да эшләргә әзер булуларын яшерми. Шуңа күрә, Аргентина Дөнья кубогын ота калса, бу иң элек Месситың җиңүе буларак кабул ителәчәк. Португалия командасында хәлләр нәкъ киресенчә булды. Дөнья чемпионаты алдыннан тавыш чыгарып, «Манчестер Юнайтед» белән араларны өзгән, хәзер үзенә яңа эш урыны эзләү белән мәшгуль булган Роналду запас, ягъни алмаш уенчыга әверелде. Чемпион калса, хәтта карьерасына нокта куярга әзер булган «йолдыз»ның хыялын исә Марокко уенчылары чәлпәрәмә китерде. Криштиануның быелгы чемпионаттагы чыгышы аның җиңелүдән соң аккан күз яшьләре белән истә калачак. Тарафдарларын бары бер нәрсә – Аргентинаның оттыруы юата алса гына инде.

Роналдуны елаткан Марокко исә дөнья чемпионатының төп ачышына әверелде. Моңа кадәр Африкадан бер генә команданың да ярымфиналга кадәр барып җитә алганы юк иде. Хәзер алар өчен бөтен Африка һәм мөселман илләре җан ата дисәк, әллә ни арттыру булмас. Плэй-оффка үз төркемендә беренче урынны алып чыккан Марокко футболчылары 5 уенда нибары 1 туп керттерде. Планетаның иң яхшы уенчылары тупланган Бельгия, Хорватия, Испания һәм Португалиягә каршы уйнап, мондый күрсәткечкә ирешү үзе үк зур мәгънәгә ия. Бу егетләрнең туктыйсы килми. Ә чиратта – Франция. Әлеге очрашу ничек кенә тәмамланса да, французларга барыбер авыр булачак. Марокко җанатарларының, яраткан командалары җиңгәч, Европа шәһәрләрендә шау-шулы бәйрәм оештыру гадәте бар. Бельгия, Германия һәм шул ук Франциядә кибетләр җимерелде, машиналар яндырылды, полиция белән бәрелешләр килеп чыкты. Җиңелүдән соң ни буласын күз алдына да китерү кыен.

Дөнья чемпионатының ярымфинал уеннары 13 һәм 14 декабрь көннәренә билгеләнгән. 18 декабрьдә буласы финалда кемнәр очрашыр? Месси белән французларның төп «йолдыз»ына әверелгән һәм Катарда 5 туп керткән Мбаппемы? Әллә инде 2018 елда Россиядә узган финалы кабатланып, төп матчка Хорватия белән Франция чыгармы? Марокконың да үз хыялы бар.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

КАЙЧАН КЕМ ЧЕМПИОН БУЛДЫ?

Ел	Чемпион	Икенче урын
1930	Уругвай	Аргентина
1934	Италия	Чехословакия
1938	Италия	Венгрия
1950	Уругвай	Бразилия
1954	ФРГ	Венгрия
1958	Бразилия	Швеция
1962	Бразилия	Чехословакия
1966	Англия	ФРГ
1970	Чехословакия	Италия
1974	ФРГ	Голландия
1978	Аргентина	Голландия
1982	Италия	ФРГ
1986	Аргентина	ФРГ
1990	Германия	Аргентина
1994	Бразилия	Италия
1998	Франция	Бразилия
2002	Бразилия	Германия
2006	Италия	Франция
2010	Испания	Голландия
2014	Германия	Аргентина
2018	Франция	Хорватия

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АЙ КҮРДЕ, КОЯШ АЛДЫ

Матурлык, сәләт һәм милли традицияләр бәйрәме. Халыкара «Татар кызы» бәйгесенең шигаре шулай яңгырый. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме? Милләт күрке – заманча татар кызы нинди булырга тиеш? Шушы сорауларга җавап эзләп, бәйгенең республикакүләм финалын тамаша кылып кайттык.

Алдан әйтеп куябыз: репортажда узган елгы республика финалы белән чагыштырулар күп булса, кичерегез. Гаеп бездә түгел…

Аера алмый тик торам…

Быел бәйгенең финалында Татарстанның шәһәр һәм районнарыннан 11 кыз катнашты. 11 декабрь кичендә узган тантанага кадәр алар, ике атна дәвамында Казанда яшәп, төрле мәдәни чараларда катнашкан, белем туплаган. Экскурсияләр, аш-су һәм кул эшләре буенча остаханәләр, Татарстанның билгеле хатын-кызлары белән очрашулар шулай ук программага кертелгән. Сәхнәдә күрсәткән иҗади номерлары да – ике атна дәвам иткән әзерлек нәтиҗәсе. Моны без видео-көндәлектән күреп белдек.

Шулай итә-итә, кызлар «Пирамида» сәхнәсенә барып җитте. Ниһаять, Татарстанның иң шәп кызлары белән безне дә таныштырасы иттеләр. Әмма, нәкъ узган елдагыча, кызлар үзләре турында үзләре сөйләмәде. Экраннан алар турындагы кыска видеоязмалар күрсәтелде, шуннан һәркайсы чиратлап ике-өч җөмлә әйтте дә, шуның белән шул. Өстәвенә кызлар барысы да бер стильдәге милли киемнән чыкты. Кершән-сөрмәле йөзләрендә дә табигатьтән бирелгән үзенчәлекләр күренмәде. Кыскасы, тамашачының кемнең-кем икәнен аңларга, кызларны истә калдырырга мөмкинлеге бик булмады. Бу урында казыйларны да җәлләп куйдым… Дөрес, кызлар арасыннан иң-иңен ачыкларга сайлап алу турлары ярдәм иткәндер. Әмма без – тамашачы бары финалны гына күрдек.

Сынауларның икенче өлешендә кызлар «Казан» бию ансамбле белән берлектә «Зәңгәр шәл»дән өзек күрсәтте. 2021 елгы финалист кызлар чыкты дип торам – әсәрен дә, җыр-биюләрен дә, киемнәрен дә үзгәртеп азапланмаганнар. Бик матур чыгыш, әмма аларның сәхнә осталыкларын күрсәтә алырдай башка әсәр юкмы икән? Югыйсә, әдәбиятыбыз бай, дибез. Ничек кенә булмасын, кызларның бу чыгышлары аларны берсеннән-берсен аерырга булса да ярдәм итте.

Биючегә сүз әйтмиләр

Оештыручылар алдан ук быелгы бәйгенең мәгърифәтчелек темасына багышлануы турында әйтеп куйды. Шунысы гаҗәп: быел интеллектуаль сынауны төшереп калдырганнар. Аның урынына булса кирәк, кызлар үз төбәкләренең күренекле хатын-кызлары турында сөйләде. Өсләрендәге күлмәкләре, башларындагы калфаклары да туры китереп сайланган иде. Ләкин бу юлы да кызларның ягымлы тавышларын озаклап тыңлый алмадык – сүзне янә бик кыска тоттылар. Бәйгенең мәгърифәтчелек темасына багышланган булуы шушында күренергә тиеш булгандыр дип аңладык.

Финалның бу өлешеннән соң алдагы елларда җиңү яулаган татар кызлары чыгыш ясады. «Татар кызы»нда кайчан да булса катнашкан кызлардан еш кына, бу – гади бәйге генә түгел, монда гомерлек дуслар табыла, дигән сүзне ишетергә туры килә. Бу чыгыш шуның бер мисалы инде.

Бәйрәм тамашасы дәвам итә торды, ә кызлар сәхнәгә бик ашыкмады. Берничә концерт номерыннан соң гына Руслан Сәйфетдинов һәм Илүсә Хуҗина башкарган җырга вальс биеде алар. Ап-ак күлмәк кигән сылулар, салмак көйгә әйләнә-әйләнә, гүя сихерләде безне. Шушы сихри биюнең тылсымнарына бирелеп китеп, кызларның кабаттан кереп югалуларын сизми дә калдык.

Гомумән, биюләргә бик бай кичә булды ул. 2023 елның Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы буларак игълан ителүен исәпкә алып, кызлар төрле халык биюләреннән торган попурри башкарды. Ирексездән 2019 елгы финал концерты искә төште. Анда да катнашучылар башка милләтләргә карата ихтирам һәм хөрмәтен шушы биюләр аша күрсәткән иде.

Милләт сагында

Шуның белән бәйгенең сынау өлешләре тәмам булды. Ике сәгатьтән артык барган тамашаның якынча бер сәгате чакырылган кунаклар – танылган җырчылар кулында иде. Янымда утырган апалар: «Бүтән чыкмыймыни соң? Концерт карарга килмәдек бит», – диеште. Чыгуын чыкты алар, тик бүләк алыр өчен генә.

Шулай итеп, матурлык, сәләт һәм милли традицияләр бәйрәме милли традицияләрсез генә узып китте. Сүз дә юк, бәлки, бу традицияләр турында бәйгенең сайлап алу турларында, ике атналык әзерлек чорында күп сөйләнелгәндер. Әмма финалда миллилеккә урын кызларның өс-башларында гына табылган иде. Шулай булуына карамастан, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров «Татар кызы» бәйгесе катнашучыларын тел, милләт сагында торучылар дип атады. Шуңа өстәп: «Кызларыбыз үзләренең мәгърифәтче татар хатын-кызларының варислары булуларын дәлилләп күрсәтә», – диде ул. Без күргән кадәре – зур бер бәйгенең бер өлеше генә шул. Ике сәгатьлек тамашадан гына ниндидер нәтиҗәләр ясау кыен, шуңа күрә кызларның Данис Шакиров әйткән сүзләргә тугрылык саклауларына ышаныйк һәм өметләник.

Инде җиңүчеләргә күчик. Елдагыча, һәр кыз бер номинациянең җиңүчесе булды. Аларның тулы исемлеге белән рәсми сайтыбызда таныша аласыз. Зәринә Әгълиуллина «Казан гүзәле – 2022» исеменә лаек булды. Ә «Татар кызы – 2022» исемен яулап, 60 мең сумлык сертификат, затлы калфак һәм хәситә иясе булып Актаныш районыннан Энҗе Габдуллина танылды. Җиңүче исеменә лаек булганын белгәч, бераз югалып калган чибәркәй әти-әнисенә, оештыручыларга, хезмәттәшләренә рәхмәт сүзләрен җиткерде. «Бу бәйгедә бик теләп катнаштым, чын күңелемнән әзерләндем һәм җаным-тәнем белән чыгыш ясадым. Бу җиңүем – шуларның нәтиҗәсе», – диде Энҗе.

Ташкентка кем бара?

Традиция буенча, «Татар кызы»ның республика этабында җиңгән кыз халыкара бәйгедә Татарстан данын якларга тиеш булачак. Ләкин бәйгенең халыкара этабы берничә ел рәттән кичектерелде. Бу юлы аны, 2023 елның язында узачак, диделәр. Үзбәкстанда узачак бәйгедә Татарстанны кем тәкъдим итәр? Аның исеме соңрак ачыкланачак.

ҮПКӘСЕЗ ТУЙ

«БОЛГАР РАДИОСЫ» Х МИЛЛИ МУЗЫКАЛЬ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫН БҮЛӘКЛӘДЕ

Эмиль Җәләлетдинов – легенда, Илүсә Хуҗина – алып баручы, елның максатчан җырчысы – Рафис Кәлимуллин… Болар «Болгар радиосы»ның Х Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасында ачыкланды. Өч сәгатьтән артык барган тамашаны «ВТ» хәбәрчесе дә карап кайтты.

«Болгар радиосы» премиясе, елдагыча, бер сәхнәдә популяр җырчыларны һәм сәхнәгә ныклы адымнарын ясаучы яшь башкаручыларны җыйды. Концертка килгән халык «Пирамида» залының фойесыннан ук бәйрәм рухына күмелде. Тамашачыларны җанлы музыка, үзенчәлекле, әкияти затлар каршы алды.

Тамаша сюрпризларга бай булды. Әйтик, милли премияне алып баручы хатын-кызның кем булуы концерт башлангач кына ачыкланды. Тантананың алыштыргысыз алып баручысы, радионың баш мөхәррире Илфар Кәримов янында быел опера җырчысы Илүсә Хуҗина урын алды.

– Алып баручы буларак, бу – минем беренче тәҗрибәм. Каушау бар, әлбәттә. Әллә нинди зур профессионал булсаң да, халык каршына, сәхнәгә чыкканда һәрвакыт дулкынланасың инде ул. Шушы рольне миңа ышанып тапшырганнарына бик рәхмәтлемен, – диде Илүсә Хуҗина.

Илфар Кәримов та яңа партнеры турында:

– Актриса, сәхнә кешесе икәне күренеп тора. Рольгә бик тиз кереп китте, – диде.

Тик җырчының беренче тәҗрибәсе булгангамы, алып баруда ниндидер киеренкелек сизелде. Һәр чыгыштан соң мәхәббәт, опера һәм эстрада арасындагы уртаклык һәм аермалар турында озын-озак сөйләшүләр дә ялыктыргыч булып тоелды. Бераз гына импровизация, динамика җитеп бетмәде.

Беренче бүлек Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган премьера – быел Болгарда куелган «Кара пулат» операсыннан өзектән башланды. Ариядән өзекне Илүсә Хуҗина башкарды. Операның композиторы Эльмир Низамов маэстро ролендә булды. Сүз уңаеннан, Эльмир Низамовны татар музыкасының асылын саклап, җыр сәнгате үсешенә керткән өлеше өчен бүләкләделәр.

Милли музыкаль премиядә барлыгы 30 номинациядә җиңүчеләр ачыкланды. «Алтын йолдыз» сыны белән ел дәвамында «Болгар радиосы»нда еш соралган һәм халык күңеленә кергән җырлар бүләкләнә. Аларны иң-иң дип табылган җырчыларга тапшырдылар. Премиянең тагын бер үзенчәлекле матур традициясе: җырчылар гына түгел, авторлар да лаеклы бүләкләрен алды.

«Алтын йолдыз» сынын беренче тапкыр алучы җырчылар да байтак иде. Араларында Илгиз Мөхетдинов, Сәйдә Мөхәммәтҗанова кебек яшь талантлы башкаручыларны күрү аеруча сөендерде.

– Бу – минем өчен зур шатлык һәм дәрәҗә. Шул ук вакытта җаваплылык та тоям. Мин күбрәк халык һәм классик әсәрләрне башкарам, үземне төрле жанрларда да сынап карарга тырышам. Тиздән джаз стилендә җырым чыгачак. Аны тыңлаучылар яратып кабул итәр дип ышанам. Джаз – татарлар өчен чит юнәлеш, диләр, ә мин алай уйламыйм. Мондый премияләр татар музыкасының бөтен төрлелеген күрергә ярдәм итә, – диде Сәйдә Мөхәммәтҗанова.

«Елның популяр җыры» номинациясендә «Алтын йолдыз»ны Филүс Каһиров алды. Кайсы җыр икәнен аңлавы кыен түгел: күптән иҗат ителгән, әмма хәзер тагын да зуррак популярлык казанган «Киек каз юллары». Кызганыч, бу юлы Артур Хәсәновны искә алмадылар. Ул әлеге җырны мобилизацияләнгән егетләрнең гимны дәрәҗәсенә күтәрде.

Татар эстрадасына ташкын булып килеп кергән җырчы. Алып баручылар аны тамашачыга шулай тәкъдим итте. Номинациясе дә махсус үзе өчен уйлап табылган кебек. Сүзем – «Иң максатчан җырчы» номинациясендә бүләкләнгән Рафис Кәлимуллин турында. Җырчы беренче «Алтын йолдыз»ын алды.

– «Болгар радиосы» премиясен тапшыру тантанасында катнашырга күптән хыяллана идем. Быел насыйп булган, димәк. Моны эшемнең нәтиҗәсе дип саныйм. Халык бик яраткан «Оныттым инде күптән» җырын башкарам, – дип сөйләде ул безгә. – Яраткан тамашачым булганда, мин һәрвакыт җаваплылык тоям. Тиздән яңа альбомым чыга, төркемем биючеләр һәм музыкантлар белән тулыланды. Әкрен генә гастрольләргә дә йөри башлыйбыз.

Җырчы Азат Фазлыев мондый премиядә катнашуны халык белән тагын да якынаю чарасы дип саный.

– Һәрбер җырчының үз урыны, үз тамашачысы. Күңелгә үтеп керә торган җырлар безне халыкка якынайта. Мондый премияләр дә шуңа бер сәбәп булып тора, – диде ул.

«Татар-информ»/Абдул Фархан

Елдагыча, премиядә «Татар эстрадасы легендасы» дигән номинация тапшырылды. Аның кемгә биреләчәген шулай ук тамаша вакытында гына белдек. Быел бу исемгә Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов лаек булды. Тере тавышка «Болгар кызы Айсолтан»ны җырлаганнан соң тагын бер җыр башкарды сәхнәне сагынган аксакал. Тамашчы да алкышларын кызганмады.

«Кайнар хит» тапшыруында җиңеп, «Тамашачы сайлавы» номинациясендә Илдар Ямалиев, Зәринә Хәсәншина, Юлия Гарифуллина, Рәфинә Ганиуллина һәм Рәзил Камалов, Гөлназ һәм Илсур Шәрипҗановлар, Мурат Гайсин, Ильвина, Алсу һәм Азат Фазлыевлар, Рамилә һәм Рамил Хәйретдиновлар, Зинира һәм Ризат Рамазановлар, Илгиз Мөхетдинов, Сәйдә Мөхәммәтҗанова бүләкләнде. Быелгы лауреатларның тулы исемлеге – сайтта. Җырчыларны 30 номинациядә бүләкләгәч, телгә алынмаган җырчы калмады да бугай инде. Хәер, монда булмаса, башкасында искә алырлар. Бездә бит бер үк җырлар төрле фестиваль-бәйгеләргә күчеп йөрүчән. Ә бу юлы, туй үпкәсез булды, дип җиңел суларга була.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 384

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+